# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Мәдәният турында

Әлеге Закон, мәдәниятнең шәхесне формалаштырудагы, үстерүдәге һәм аның үз-үзен танытудагы, җәмгыятьне гуманлаштырудагы, Татарстан Республикасы халкының үзенчәлеген һәм традицияләрен саклап калудагы төп ролен танып, Татарстан Республикасы территориясендә мәдәниятне үстерүнең хокукый, икътисадый, оештыру нигезләрен билгели һәм ул мәдәният өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салуга юнәлдерелгән.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

**1 статья. Мәдәният турындагы законнар**

Мәдәният турындагы законнар Татарстан Республикасы Конституциясенең тиешле нигезләмәләреннән, әлеге Законнан һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка закон актларыннан тора.

**2 статья. Мәдәният турындагы Татарстан Республикасы законнарының бурычлары**

Мәдәният турындагы Татарстан Республикасы законнарының бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы гражданнарының мәдәният казанышларыннан файдалануга конституциячел хокукларын яклауны тәэмин итүдән;

мәдәни хәзинәләрне булдыру, тарату, үзләштерү һәм саклап калу мөнәсәбәтләрне җайга салудан;

татар милли мөдәнияте, Татарстан Республикасының күпмилләтле халкының мәдәнияте үсешенә, аның дөнья мәдәниятенә интеграцияләнүенә булышлык итүдән;

мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәте принципларын билгеләүдән.

**<u>3 статья.</u> Төп төшенчәләр**

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

мәдәни эшчәнлек - мәдәни хәзинәләрне саклап калу, булдыру, тарату һәм үзләштерү эшчәнлеге ул;

мәдәни хәзинәләр - әхлакый һәм эстетик идеаллар, үз-үзеңне тоту нормалары һәм үрнәкләре, телләр, диалектлар һәм сөйләшләр, милли традицияләр һәм гореф-гадәтләр, йолалар, тарихи топонимнар, халык авыз иҗаты, нәфис сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре, әдәбият, сәнгать әсәрләре, мәдәни эшчәнлектәге фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәләре һәм ысуллары, тарихи-мәдәни әһәмияткә ия биналар, корылмалар, әйберләр һәм технологияләр, тарихи-мәдәни яктан уникаль территорияләр һәм объектлар ул;

мәдәни уңайлыклар - гражданнарга үзләренең мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен юридик һәм физик затлар тарафыннан бирелә торган шартлар һәм хезмәт күрсәтүләр ул;

иҗади эшчәнлек - мәдәни хәзинәләр иҗат итү һәм аларны интерпретацияләү ул;

иҗади хезмәткәр - мәдәни хәзинәләрне иҗат итүче яисә аларны интерпретацияләүче, үзенең иҗади эшчәнлеген тормышының аерылгысыз өлеше дип санаучы, хезмәттәге хокукый мөнәсәбәтләре белән бәйле булу-булмавына, иҗади хезмәткәрләрнең нинди дә булса ассоциациясендә әгъза булып тору-тормавына карамастан, иҗади хезмәткәр буларак танылган яисә бу сыйфатта танылырга тиешле физик зат ул;

мәдәни мирас - кеше яисә табигать тудырган матди һәм рухи хәзинәләр, шулай ук халыкның, җәмгыятьнең, күренекле шәхесләрнең тарихи, фәнни-техник, сәнгати, табигый-экологик, этнологик яисә башка мәдәни әһәмияткә ия рухи тормыш нәтиҗәләре ул;

Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни байлыгы - мәдәни хәзинәләр бергәлеге, шулай ук Татарстан Республи-

касының дәүләт әһәмиятенә ия булган мәдәният оешмалары ул. Татарстан Республикасы территориясендә федераль әһәмияткә ия мәдәни хәзинәләр һәм мәдәният оешмалары булырга мөмкин;

мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәте - мәдәниятләрне саклап калу, булдыру, тарату һәм үзләштерү эшчәнлегендә дәүләт таянып эш итә торган принциплар һәм нормалар бергәлеге, шулай ук мәдәният өлкәсендә дәүләтнең үз эшчәнлеге ул.

**4 статья. "Мәдәният турында" Татарстан Республикасы Законын куллану өлкәсе**

Әлеге Закон түбәндәге өлкәләрдә мәдәни эшчәнлекне җайга сала:

мәдәни хәзинәләрне ачыклау-табу, өйрәнү, саклап калу, реставрацияләү һәм алардан файдалану;

матур әдәбият, кинематография, сәхнә сәнгате, пластик һәм музыкаль сәнгать, архитектура һәм дизайн, фото сәнгате, сәнгатьнең башка төрләре һәм жанрлары;

халыкның нәфис сәнгать һөнәрчелеге һәм кәсепләре, телләр, диалектлар һәм сөйләшләр, халык авыз иҗаты, гореф-гадәтләр һәм йолалар, тарихи топонимнар;

үзешчән (һәвәскәр) сәнгать иҗаты;

музей эше һәм коллекцияләр туплау;

китап нәшер итү һәм китапханә эше, шулай ук законнар нигезендә басма әсәрләр булдыруга, аларны таратуга һәм алардан файдалануга бәйле башка мәдәни эшчәнлек, архив эше;

телевидение, радио һәм мәдәни хәзинәләрне булдыру, аларны тарату буенча башка төр аудиовизуаль чаралар;

мәдәният өлкәсендә эстетик тәрбия, сәнгать белеме бирү һәм педагогик эшчәнлек;

мәдәният өлкәсендә фәнни тикшеренүләр;

халыкара мәдәни алмашулар;

мәдәни хәзинәләрне саклап калу, булдыру, тарату һәм үзләштерү өчен кирәк булган материалларны, җиһазларны һәм башка чараларны җитештерү;

мәдәни хәзинәләрне саклап калуга, булдыруга, таратуга һәм үзләштерүгә юнәлдерелгән башка төр эшчәнлек.

**5 статья. Мәдәният әлкәсендә дәүләт сәясәтенең теп принциплары**

Татарстан Республикасында мәдәният әлкәсендә дәүләт сәясәте түбәндәге төп принциплар нигезендә корыла:

Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләрне булдыруда, саклап калуда, таратуда һәм үзләштерүдә халыкларның тигез хокуклылыгы;

гомумкешелек рухи хәзинәләрнең өстенлеге;

иҗади эшчәнлек иреге;

интеллектуаль милекне яклау;

мәдәни хәзинәләрнең гомуми файдаланылышы;

мәдәни эшчәнлекне оештыруда дәүләт һәм җәмәгать башлангычларының бергәлеге.

## II булек. Мәдәният өлкәсендә кеше хокуклары һәм иреге

**6 статья. Мәдәният өлкәсендә кеше хокуклары һәм иреге**

Татарстан Республикасында һәр кеше түбәндәге хокукларга ия:

үз мәнфәгатьләре һәм сәләтләре нигезендә иҗат эшчәнлеге иреге;

шәхси мәдәни үзенчәлек;

профессиональ яисә профессиональ булмаган иҗат эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

законнарда билгеләнгән очраклардан гайре, дәүләтнең мәдәни хәзинәләреннән файдалану мөмкинлеге;

иҗат берлекләренә, ассоциацияләренә, җәмәгать берләшмәләренә законнар нигезендә берләшү;

законнарда билгеләнгән тәртиптә мәдәни хәзинәләрне җитештерү, ишәйтү һәм тарату оешмалары төзү;

Татарстан Республикасыннан читтә мәдәни эшчәнлек.

**7 статья. Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни үзенчәлеген саклау һәм үстерү**

Татарстан Республикасының күпмилләтле халкы үзенең мәдәни

үзенчәлеген саклап кала һәм үстерә, борынгы мәдәни-тарихи һәм табигый яшәеш тирәлеген яклый, торгыза һәм саклап кала.

Татарстан Республикасы тарихи традицияләрне, халык иҗатын, халык иҗатын, гореф-гадәтләрне, йолаларны, бәйрәмнәрне, традицион һөнәрчелекне һәм кәсепләрне, милли шәһәр төзелешенең архитектура рәвешләрен, декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләрен торгызу һәм үстерү өчен шартлар тудыра.

**<u>8 статья.</u> Чит ил гражданнарының һәм гражданлыксыз затларның мәдәният өлкәсендә хокуклары**

Чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә Татарстан Республикасы гражданнары белән бертигез хокукларга ия булалар. Чит ил гражданнары һәм гражданлыксыз затлар өчен мәдәни эшчәнлекнең махсус шартлары закон белән билгеләнә.

## Ш бүлек. Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни байлыгы

**<u>9 статья.</u> Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни байлыгы объектларын дәүләт исәбенә алу**

Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни байлыгы объектлары законнар нигезендә дәүләт исәбенә алынырга тиеш.

**<u>10 статья.</u> Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни байлыгы объектлары режимы**

Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни байлыгы объектлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты рөхсәтеннән башка бер урыннан икенче урынга күчерелә яисә үзгәртелә алмыйлар.

Мәдәни байлык объектларыннан файдалану аларның тарихи, фәнни, сәнгати яисә башка мәдәни әһәмияте нигезендә гамәлгә ашырыла. Мәдәният оешмалары мәдәни ядкярләрдән өстенлекле файдалану хокукына ия булалар.

Мәдәни байлык объектларын тиешле халәттә тоту һәм саклап

калу вазыйфалары аларның милекчеләренә яисә алардан файдаланучыларга йөкләнә. Мәдәни байлык объектларының сакланышын тәэмин итү Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарына, җирле үзидарә органнарына йөкләнә.

Татарстан Республикасы күпмилләтле халкының мәдәни байлык объектларын биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

**11 статья.** **Татарстан Республикасының китапханә, музей, архив һәм башка фондлары**

Татарстан Республикасының китапханә, музей, архив, кино-,фото һәм башка фондларының мәдәният өлкәсендә бөтенлеге, аларны саклау, аларның эшчәнлеге һәм аларны үстерү тәртибе дәүләт тарафыннан тәэмин ителә.

## IV бүлек. Иҗади хезмәткәрләрнең статусы

**12 статья.** **Дәүләт һәм иҗади хезмәткәрләрнең хәле**

Татарстан Республикасы:

мәдәни эшчәнлектә иҗади хезмәткәрнең аерым ролен таный;

иҗат ирегең, икътисадый һәм социаль хокукларны гарантияли;

иҗади хезмәткәрләрнең халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә, мәдәниятне саклап калуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлеген кызыксындыра;

иҗади хезмәткәрләргә хезмәт шартлары тудыра һәм аларны эш белән тәэмин итә;

иҗади эшчәнлекнең үзенчәлеген исәпкә алып, законнар нигезендә иҗади хезмәткәрләрне социаль яклау системасын камилләштерә;

иҗади хезмәткәрләргә халыкара иҗади элемтәләрне киңәйтүдә ярдәм итә.

**13 статья.** **Дәүләт һәм иҗади хезмәткәрләрнең оешмалары**

Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр оешмаларын, шулай ук профессиональ иҗади хезмәткәрләрнең халыкара оешмалары-

ның филиалларын һәм бүлекчәләрен булдырырга ярдәм итә.

Иҗади хезмәткәрләр оешмалары дәүләт белән мөнәсәбәтләрдә тигез хокуклы булалар.

Татарстан Республикасы иҗади хезмәткәрләр оешмаларына мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен әзерләүдә һәм аны гамәлгә ашыруда катнашу мөмкинлеген тәэмин итә.

**14 статья. Иҗади заказлар**

Социаль һәм мәдәни бурычларны хәл итү, иҗади эзләнүләрне кызыксындыру өчен дәүләт органнары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, физик затлар яңа сәнгать әсәрләре иҗат итү, мәдәни-агарту гамәлләре уздыру йөзеннән максатчыл иҗади заказлар (шул исәптән конкурс нигезендә) ясый алалар.

## V бүлек. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнарының, җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендә компетенцияләре

**15 статья. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният өлкәсендә вәкаләтләре**

Мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карамагына түбәндәгеләр керә:

мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен билгеләү һәм иң мөһим республика программаларын раслау;

мәдәният өлкәсен законнар белән җайга салу;

Татарстан Республикасы республика бюджетының мәдәният өчен чыгымнар өлешен раслау;

законнар нигезендә салым буенча өстенлекле ташламалар билгеләү.

**16 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының мәдәният өлкәсендә вәкаләтләре**

Мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карамагына түбәндәгеләр керә:

мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру һәм дә-

үләт программаларын гамәлгә ашыру;

законнар нигезендә халыкара мәдәни алмашуларны җайга салу, мәдәният өлкәсендә тышкы икътисадый эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

дәүләт мәдәният оешмаларын финанслау тәртибен, мәдәният хезмәткәрләрен матди тәэмин итү нормаларын һәм төрләрен билгеләү;

законнар нигезендә өстенлекле ташламалар бирү;

республика буйсынуындагы дәүләт мәдәният оешмаларын законнар нигезендә төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү;

мәдәни хәзинәләрне дәүләт исәбенә алу тәртибен билгеләү.

**17 статья. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы компетенцияләре**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы карамагына түбәндәгеләр керә:

мәдәният өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру;

дәүләт исеменнән мәдәни хәзинәләр сатып алу;

мәдәни эшчәнлекне мәгълүмати һәм фәнни-ысулый тәэмин итү;

мәдәни хәзинәләрне дәүләт исәбенә алуны гамәлгә ашыру;

мәдәният өлкәсендә ысулый күрсәтмәләр әзерләү һәм раслау;

мәдәният оешмалары челтәрен үстерүне фаразлау.

**18 статья. Дәүләт хакимияте һәм идарәсе җирле органнарының, җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендә компетенцияләре**

Халык депутатлары җирле Советларының мәдәният өлкәсендәге компетенцияләренә түбәндәгеләр керә:

законнар нигезендә мәдәният мәсьәләләрен карау һәм хәл итү;

мәдәниятне үстерүнең җирле программаларын карау һәм раслау;

җирле бюджетның мәдәният өчен чыгымнар өлешен раслау;

законнар нигезендә районда, шәһәрдә мәдәният үсешен кы-

зыксындыра торган салым ташламаларын билгеләү;

мәдәният турында Татарстан Республикасы законнарының үтәлешен тикшереп тору.

Җирле администрациянең мәдәният өлкәсендәге компетенцияләренә түбәндәгеләр керә:

законнар нигезендә дәүләт идарәсенең мәдәният өлкәсендәге җирле органнарын төзү һәм бетерү, аларның структураларын һәм вәкаләтләрен билгеләү, дәүләт идарәсенең мәдәният өлкәсендәге җирле органнары җитәкчеләрен билгеләп кую;

дәүләт идарәсенең мәдәният өлкәсендәге җирле органнары эшчәнлеген тикшереп тору;

җирле бюджет проектын, мәдәниятне финанслауның җирле нормативларын әзерләү;

мәдәният учреждениеләрен кадрлар белән тәэмин итү чараларын, аларны социаль яклау чараларын күрү;

мәдәниятнең коммуналь учреждениеләре биналарын һәм корылмаларын төзү.

Җирле үзидарә органнарының мәдәният өлкәсендәге компетенцияләренә түбәндәгеләр керә:

җирле бюджетларның мәдәният өчен чыгымнар өлешен формалаштыру;

җирле әһәмияткә ия мәдәният учреждениеләренең биналарын һәм корылмаларын төзү;

мәдәният оешмаларының эшен камилләштерү буенча чаралар күрү;

җирле халыкның мәдәни традицияләрен саклау һәм үстерү.

## VI бүлек. Мәдәният өлкәсен икътисадый җайга салу

### 19 статья. Мәдәният өлкәсендә милек рәвешләре

Татарстан Республикасында мәдәни хәзинәләргә, шул исәптән биналарга, корылмаларга, мөлкәти комплексларга, җиһазларга һәм мәдәни максатларда файдаланыла торган башка мөлкәткә карата законнар нигезендә барлык милек рәвешләре дә рөхсәт ителә.

**20 статья.** **Мәдәният өлкәсендә хосусыйлаштыру**

Законнарда каралган очраклардан гайре, Татарстан Республикасының мәдәни хәзинәләре хосусыйлаштырылмый.

**21 статья.** **Татарстан Республикасында мәдәниятне һәм мәдәни эшчәнлекне финанслау чыганаклары**

Мәдәният өлкәсендә финанс чаралары түбәндәгеләр исәбеннән формалаштырыла:

Татарстан Республикасының республика бюджетыннан һәм җирле бюджетлардан мәдәнияткә ассигнованиеләр;

мәдәният оешмалары эшчәнлегеннән керемнәр;

юридик һәм физик затлардан, шулай ук халыкара оешмалардан ирекле кертемнәр, иганәләр;

законнарда тыелмаган башка чыганаклардан керүче акчалар.

Мәдәниятне дәүләттән финанслау күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасының республика бюджетын һәм җирле бюджетларны раслаганда билгеләнә.

Мәдәният оешмаларын дәүләттән финанслау күләмнәре һәм нормативлары инфляция темплары нигезендә индексацияләнергә тиеш.

Өстәмә акчалар җәлеп итү мәдәниятне бюджеттан финанслауны киметүгә китерми.

Финанс чараларын куллану мәдәният оешмасының уставы нигезендә гамәлгә ашырыла. Агымдагы хисап чорында кулланылмаган акчалар кире алынмый һәм киләчәктә устав максатлары өчен кулланыла.

Мәдәният оешмалары законнарда билгеләнгән тәртиптә банк кредитларыннан файдалана алалар.

**22 статья.** **Мәдәниятне үстерү фондлары**

Гражданнар һәм юридик затлар законнар нигезендә мәдәниятне үстерү фондларын гамәлгә куярга хокуклы.

**23 статья.** **Дәүләт мәдәният оешмаларының эшкуарлык эшчәнлеге**

Дәүләт мәдәният оешмалары законнарда билгеләнгән тәртиптә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыра алалар.

**24 статья.** **Мәдәният өлкәсендә инвестиция сәясәте**

Татарстан Республикасында мәдәниятнең матди-техник базасын ныгыту һәм үстерү өчен өстенлекле рәвештә дәүләт капитал салулары бүлеп бирелә.

Мәдәни объектлар буенча капитал салулар бүлү дәүләт идарәсенең тиешле органнары тарафыннан билгеләнә.

**25 статья.** **Мәдәниятне матди-техник тәэмин итү**

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары мәдәният оешмаларында яңа техника һәм технологияләрне үзләштерүне тәэмин итүче фәнни-техник сәясәтне билгелиләр һәм гамәлгә ашыралар.

Дәүләт мәдәният оешмаларының матди-техник базасын үстерү бюджет акчалары һәм оешмаларның үз акчалары чикләрендә аларның үзләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары иҗат хезмәткәрләренә, берлекләренә һәм коллективларына законнар нигезендә иҗади эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру өчен файдалануга үз вәкаләтләре чикләрендә биналар бирәләр.

Махсус җиһазландырылган корылмаларны, төзелмәләрне, биналарны иҗат остаханәләре, студияләре сыйфатында файдаланучы мәдәният эшлеклеләренә, шулай ук торак мәйданын халык өчен ачык булган дәүләткә карамаган музейлар, китапханәләр һәм башка мәдәният оешмалары оештыру максатында файдаланучы затларга законнарда билгеләнгән тәртиптә мөлкәткә салым ташламалары бирелергә мөмкин.

Мәдәният оешмалары урнашкан биналарны башка оешмаларга тапшырганда, аларны тапшыру турында карарлар чыгаручы дәүләт идарәсе органнары аларга законнарда билгеләнгән тәртиптә шундый ук биналар бирәләр.

**26 статья.** **Мәдәният өлкәсендә бәяләр һәм бәя кую**

Түләүле хезмәт күрсәтүләр өчен бәяләр (тарифлар), шул исәптән билет һәм продукция бәяләре, мәдәният оешмалары тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә.

Түләүле мәдәни гамәлләрне оештырганда мәдәният оешмалары халыкның аерым категорияләренә законнар нигезендә өстенлекле ташламалар бирә алалар.

**27 статья.** **Мәдәният оешмаларының башка эшчәнлек елкәсе оешмалары белән үзара мөнәсәбәтләре**

Мәдәният оешмалары мәдәният һәм мәдәни байлык объектларының, мәдәният эшлекләләренең сурәтләре төшерелгән (күчереп ясалган) продукцияне (шул исәптән реклама продукциясен) бу объектларны биләүчеләрнең һәм сурәтләре төшерелгән затларның рәсми рөхсәте белән законнар нигезендә әзерли һәм сата алалар.

Юридик һәм физик затлар мәдәният объектларында туристлык-экскурсия эшчәнлеген бары тик законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә торган лицензия нигезендә генә тормышка ашыралар.

Тарихи торак пунктларында, мәдәният ядкярләрен саклау зоналарында урнашкан оешмалар (бюджет оешмаларыннан тыш) тегәл билгеләнгән түләүләрне Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә күчерәләр.

**28 статья.** **Мәдәният хезмәткәрләрен социаль яклау**

"Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законы мәдәният уку йортларының педагогия хезмәткәрләренә дә кагыла.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар үз компетенцияләре нигезендә үз акчалары исәбеннән мәдәният хезмәткәрләренә законнарда билгеләнгән тәртиптә өстәмә социаль ташламалар бирә алалар.

**29 статья.** **Мәдәният хезмәткәрләрен бүләкләү**

Мәдәниятне үстерүдә, иҗади кадрлар тәрбияләүдә һәм әзерләүдә күрсәткән аерым хезмәтләре өчен, мәдәниятне үстерүгә үз-

ләреннән зур өлеш кертүләре өчен мәдәният хезмәткәрләре дәүләт бүләкләре белән бүләкләнүгә, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең мактаулы исемнәрен бирүгә, премияләр һәм матди бүләкләүнең башка төрләрен бирүгә тәкъдим ителә алалар.

## VII бүлек. Татарстан Республикасының башка дәүләтләр белән мәдәни алмашулары

### 30 статья. Халыкара мәдәни алмашулар һәм Татарстан Республикасының халыкара шартнамәләре

Татарстан Республикасы халыкара мәдәни багланышларның субъектлары даирәсен киңәйтүгә булышлык итә, физик затларның, мәдәният оешмаларының, учреждениеләренең мәдәни алмашуларда мөстәкыйль катнашуларын хуплый.

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә әлеге Законда каралганнан башкачарак кагыйдәләр билгеләнгән булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

### 31 статья. Халыкара мәдәни алмашулар сәясәте һәм аның өстенлекләре

Татарстан Республикасының халыкара мәдәни алмашуларының өстенлекле юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

мәдәни хәзинәләрне уртак җитештерү;

сирәк очрый торган тарихи һәм мәдәни ядкярләрне саклау һәм реставрацияләү;

мәдәният хезмәткәрләрен әзерләү һәм аларны стажировкалау;

мәдәни эшчәнлек өчен яңа технологияләр, техник чаралар, җиһазлар булдыру һәм аларны файдалануга кертү;

мәдәният өлкәсендәге ысулиятләр, уку-укыту программалары һәм кулланма әсбаплар белән алмашу.

### 32 статья. Татарстан Республикасыннан читтә булган ватандашлар белән мәдәни багланышлар

Татарстан Республикасы үзеннән читтәге ватандашларының мәдәният оешмалары белән күпьяклы мәдәни багланышлар урнаштыра

һәм аларны киңәйтә, аларның якташлык җәмгыятьләре белән хезмәттәшлек итә, мәдәни үзәкләрен булдыруда аларга булышлык күрсәтә, алар белән уртак мәдәни гамәлләр уздыра.

**33 статья.** Халыкара мәдәният оешмаларында катнашу

Татарстан Республикасы территориясендә халыкара мәдәни фондларның һәм оешмаларның законнарга каршы килми торган эшчәнлек белән шөгыльләнүче филиаллары һәм башка структуралары төзелергә мөмкин. Теләсә нинди юридик зат халыкара мәдәни оешмаларның уставларында билгеләнгән тәртип нигезендә аларга керергә хаклы.

## VIII бүлек. Йомгак нигезләмәләр

**34 статья.** Әлеге Законны бозган өчен җаваплылык

Әлеге Законны бозган өчен законнар нигезендә юридик җаваплылык билгеләнә.

**35 статья.** Әлеге Законны гамәлгә кертү турында

Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 3 июле
N I705